КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 18 декабрь г.Казань № 1170

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 ноябрь, 863 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау буенча дәүләт комитетына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль)

әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибендә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы булып Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тора (алга таба – дәүләт органы).»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы дәүләт органының вазыйфаи затлары булып түбәндәгеләр тора:

рәис;

рәис урынбасары;

дәүләт күзәтчелеге (контроле) һәм суд-административ практика бүлеге башлыгы;

мәдәни мирас объектларын саклау бүлеге башлыгы;

мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм археология бүлеге башлыгы;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге секторы мөдире;

дәүләт күзәтчелеге (контроль) һәм суд - административ практика бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

мәдәни мирас объектларын саклау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

мәдәни мирас объектларының археология һәм исәпкә алу бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге секторының әйдәп баручы киңәшчесе;

дәүләт күзәтчелеге (контроль) һәм суд - административ практика бүлегенең әйдәп баручы белгече;

мәдәни мирас объектларын саклау бүлегенең әйдәп баручы белгече.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин